**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**КУЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422612, РТ, Лаишевский район,
п. Мысовский, ул.Центральная, д.33 а
тел: 89061111775, kuuk.la@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
422612, РТ, Лаеш район, Мысовский
поселок, Центральная ур, 33 а йорт
тел: 89061111775, kuuk.la@tatar.ru

**2024елның 16 декабре** **58 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлеге башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлеге башкарма комитетына:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлеге Советының 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын әзерләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшырырга.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-

http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Көек**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Л.М. Сатдинова**